**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 август № 605

г. Казань

2015 – 2019 елларда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыеннарында кергән мәсьәләләрне хәл итү буенча чаралар комплексын («юл картасын») раслау турында

Татарстан Республикасы территорияләрен үстерүнең проблемалы мәсьәләләрен хәл итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән 2015 – 2019 елларда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнар җыеннарында кергән мәсьәләләрне хәл итү буенча чаралар комплексын («юл картасын») (алга таба – «юл картасы») расларга.

2. Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарына тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына һәм оешмаларга тәкъдим итәргә:

2015 елның 1 сентябренә кадәр «юл картасы» чараларын дәүләт һәм муниципаль программаларга кертергә;

«юл картасы» чараларын фаразланган вакытларда үтәргә;

квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 көненә кадәр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «юл картасы» чараларын үтәү турында хисаплар тапшырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\605.docx